**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әлкәй авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Әлкәй авылы №68 «16» октябрь 2017 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Советының 2013 елның 08 февралендәге 46 номерлы карары белән расланган үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары һәм тәртибе турындагы Нигезләмәгә өстәмәләр кертү хакында ( 14.07.2016 №34 карар редакциясендә)

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 июнендәге 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, “Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында” 2007 елның 17 декабрендәге 722 номерлы, “Муниципаль берәмлекләр башлыкларын, депутатларны акчалата бүләкләү күләмнәрен индексацияләү турында” 2017 елның 28 июлендәге 525 номерлы карары, “Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, контроль-хисап органнары рәисләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфаи окладлары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә

Әлкәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Советының 2013 елның 08 февралендәге 46 номерлы карары белән расланган үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары һәм тәртибе турындагы Нигезләмәне (14.07.2016 №34 карар редакциясендә) әлеге карарга №1, 2 кушымта нигезендә тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис С.З.Зиннурова

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге 2017 елның 17 октябрендәге 26 номерлы карарына №1 кушымта

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларының иң чик күләмнәре

| Вазифалар атамасы | Айлык вазыйфаи окладның күләме (сум) |
| --- | --- |
| | 12 төркем |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары (секретаре) | 2889 |
| Әйдәп баручы белгеч | 2234 |
| 1 категорияле белгеч | 2158 |
| 2 категорияле белгеч | 2054 |
| Белгеч | 2054 |

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге 2017 елның 17 октябрендәге 26 номерлы карарына №2 кушымта

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирлек башлыгына, депутатларына, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларына акчалата түләү күләме

| Вазифалар атамасы | Акчалата түләү күләме (сум) |
|---|---|
| | 12 төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 11701 |
| Депутат | 8621 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы | 7337 |